ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

423747, Киров авылы,
Киров урамы,52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

**«04» октябрь 2024 ел** **№ 9**

Киров авыл җирлеге башкарма комитетының

2015 елның 15 октябрендәге 8 номерлы карары белән расланган,

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 01 декабрендәге 2151 номерлы карары нигезендә, Киров авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Киров авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 15 октябрендәге 8 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Федераль законның 82 статьясы нигезендә сатып алулар гамәлгә ашырылган очракта план-графикка үзгәрешләр кертү сатып алуларда катнашучыларга котировкалар бирү турында гарызнамә җибәрелгән көннән дә соңга калмыйча, ә Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты нигезендә бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алу башкарылган очракта - контракт төзелгән көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»

1.2. 11 пунктны РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 30 сентябрендәге «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау тәртибен билгеләү, мондый

план-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графикларын урнаштыру, мондый план-графикларга мәгълүмат кертү үзенчәлекләре һәм сатып алу план-графиклары формасына таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 1279 номерлы карары нигезендә үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. План-график Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый планнарга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графикларын урнаштыру, мәгълүматны сатып алуларның план-графикларына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүнең план-графигы формасына карата таләпләр нигезендә формалаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http//pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет житәкчесе: И.Х.Магданов